МБДОУ «Солнышко»

# Нурчыклар

*Буа районы “Кояшкай” балалар бакчасы гәҗите*

**№7 Март, 2021 ел**




11март көнне район мәдәният йортында «Татар кызчыгы, татар малае -2021» республика конкурсының район этабы узды.Безнең балалар бакчасыннан Газизуллина Әминә катнашып «Иң мөлаем кыз»номинациясендә җиңүче булды.Барлык катнашучылар да кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнделәр.Әминәгә киләчәктә уңышлар телибез.

## Бүгенге санда

1. Татар кызчыгы, татар малае - 2021
2. Нәүрүз мөбәрәкбад!
3. Широкая масленица

### Кадерле гәҗит укучыларыбыз!

**Сезнең кулда балалар бакчасында электрон рәвештә чыгып килүче “Нурчыклар” гәҗитенең басма саны. Газетаның электрон вариантының адресы:**

**https://edu.tatar.ru/buinsk/dou/solnyshko/page4539321.htm**

***Хөрмәтле балалар, хезмәткәрләр, әти - әниләребез!***

Нәүрүз - борынгы әби - бабаларыбыз үткәргән язны каршылау бәйрәме ул. Мәгълүм булганча, 18 нче гасырга хәтле татар халкы Яңа елны март аеның 21 ендә - көн белән төн тигезләшкән вакытта каршы алган. Бу көн Иран календаре нигезендә “Нәүрүз” дип аталган. Иранда һәм аңа күрше илләрдә яңа елны хәзер дә март аенда каршы алу гадәте яшәп килә. “Нәүрүз” сүзе фарсы-таҗик телендә “Яңа көн” дигән мәгънәне аңлата. Борынгы бәйрәм атна буе дәвам иткән. Һәр көннең үз гадәте, үз тәртибе, язылмаган кануннары булган: 7 көн буена туган - тумачаларга, күрше - күләнгә миһербанлык кылганнар, ата-баба каберенә барганнар, сугышлар тукталып торган. Бу көнне яшьләр шәкертләр, балалар, өйдән-өйгә кереп бәет, шигырь әйткәннәр, йорт хуҗасына исәнлек-саулык, иминлек-байлык, бәхет, уңышлар теләгәннәр. Бу шәкертләрнең күңел ачу чарасы гына булып калмаган. Шулай йөреп, алар авылдашларының күңелен күтәргәннәр, асылда салкын кышлар бетеп килүгә бергәләшеп шатланганнар, язны каршылаганнар.

Сезне халкыбыз йолаларының берсе-Язгы Яңа ел-Нәүрүз бәйрәме белән котлыйм. Саулык-сәламәтлек, бәхет, уңышлар телим. Барлык өметләрегез дә тормышка ашсын, Язгы Яңа ел котлы булсын! Нәүрүз мөбәрәкбад!

Бу язгы бәйрәм өйләребезгә тынычлык, иминлек һәм игелек белән килеп керсен! Чын күңелдән барыгызда да нык сәламәтлек, гаилә бәхете телим! Йортларыгызда һәрвакыт татулык, фикер бердәмлеге патшалык итсен!

***Иң изге теләкләр белән Э.З.Абузәрова***

# Яз килә, Нәүрүз килә!








19 март көнне, "Кояшкай" балалар бакчасында “Нәүрүз” бәйрәме үтте. Атна буе балалар бу бәйрәмгә әзерләнделәр, аны түземсезлек белән көттеләр. Балалар язны каршылап жыр жырладылар, биеделәр, татар халык уеннары уйнадылар. Кыюлык һәм житезлек буенча көч сынаштылар. Бәйрәм ”Карга боткасы” ашау белән тәмамланды

*Хуш киләсең, гүзәл Нәүрүз,*
*Язгы Яңа елыбыз!*
*Яңа елда туры булсын,*
*Нурлы булсын юлыбыз!*








# Широкая Масленица





12 марта в нашем детском саду прошло масленичное гуляние. Дети готовились к этому событию и ждали его с нетерпением. Ребята кружились в хороводе, а затем играли в веселые русские народные игры, соревновались в смелости и ловкости. По старой доброй традиции наш праздник посетил председатель ТСО "Мелиоратор" Гиматдинова М.Ш. с подарками для детей. Праздник закончился угощением вкусными блинами.





# "Нәүрүз" бәйрәмендә балалар белән уйнар өчен уеннар

## Җырлы – биюле уен «Тамчы, там!»



Уенчылар, пар-пар булып, кулга-кул тотынышып, бер-бер артлы басалар. Алар түбәнәге җырларны бергәләп җырлыйлар һәм бию хәрәкәтләре ясыйлар:

Там, там, тамчы, там, *(Балалар алга баралар)*
Тамганыңны яратам. (*артка таба чигенәләр)*
Тамган тамчыларга карап, (*кара-каршы басып*
Мин җырларга яратам. *кул чабалар).*

Тамчы тама, тамчы тама,
Тамчы тама түгелме?
Тамчы тамса, матур язлар
Килеп җитә түгелме?

Без уйныйбыз, уйныйбыз,
Якты көннән туймыйбыз.
Кулны кулга чаба-чаба
Көләбез дә җырлыйбыз.

Уен шул рәвешчә дәвам итә

## Җырлы – биюле уен «Коймаклар»

Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Кырыйдагы балалар түгәрәк буенча әйләнеп җырлыйлар:

Ямьле бәйрәм көн иде,
Чакырдык без кунаклар.
Кунакларны сыйларга
Салдык майлы коймаклар.
Чыж-чыж итеп коймаклар *(Балалар кулларын як- якка җәяләр)*
Җәелде, әй, җәелде.
Менә тагын кечкенә (*кысылалар)*
Булып калды, җыелды



Аннан ары кабарды, (*кулларын югары күтәрәләр)*
Кабарды, әй, кабарды.
Шиңде, юп-юка калды. (*чүгәлиләр)*
Пеште инде коймаклар.
Сыйландылар кунаклар,
Тордылар, баш иделәр, (*баш ияләр)*
Таралдылар, әй, шатлар,

## Җырлы – биюле уен «Нардуган»




Бер бала уртага чыгарыла. Башка балалар аның тирәсендә бер түгәрәк ясап, кулга-кул тотынышып, шушы нардуган җырын җырлап әйләнәләр. Ул үзенә бер көйгә җырлана.

*Син уртада, без кырыйда,*
*Әйләнәбез, Нардуган,*
*Син нишләсәң, ни кылансаң,*
*Мин дә шуны булдырам!*

Җыр беткәндә, уртадагы бала нинди дә булса бер хәрәкәт ясый, түгәрәктәге балалар да шул хәрәкәтне ясыйлар. Кем шуны булдыра алмый, уртадагы бала үз урынына аны чыгара, һәм уен баштагыча дәвам итә.

## Башваткычларның җавабын тап!


Рәсемнәргә кара һәм әйт: бу хайваннарның кайсысы — авылда, кайсысы урманда яши?



Диалогны өйрән, дустың белән сөйләш.

— Син кошларны яратасыңмы?
— Әлбәттә.
— Ә быел җимлек ясадыңмы?
— Әйе.
— Кая элдең?
— Бакчага.

Кроссвордны чиш.





**1—2.** Йорт кошлары.
**3.** Җылы якка китүче кош.
**4.** Сары түшле кош (птица с жёлтой грудкой)

## Словесное фигурное катание. Переведите слова на татарский язык

**Начинают катание с чёрного квадратика. Читая определения, с помощью карандаша прокладывайте путь, по вертикали, горизонтали и диагонали. Главное условие: никакое слово не должно «ломаться», т.е. внезапно менять свое направление.**

**Последняя буква одного слова служит первой для другого.**

**В конце игры, на поле получится какой-либо узор или фигура.**

1. Летучая мышь.
2. Палка.
3. Внезапно.
4. Сытый.
5. Щавель.
6. Обгорелое полено.
7. Пищевод.
8. Бахрома.
9. Вечер.
10. Лыжи.
11. Хвоя.
12. Стража.
13. Крыло.
14. Торжество.
15. Голодный.
16. Висок.
17. Этика.
18. Соболь.
19. Условие.

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ә | а | ы | р | ә | о | о | к | ы | м | к | р | с | к | м | а |
| л | д | г | а | ш | м | в | п | р | а | б | и | а | е | ш | р |
| л | ы | с | к | ш | е | т | е | л | р | е | б | с | к | о | л |
| б | а | ч | а | я | а | к | а | ә | г | и | ч | а | ә | т | а |
| р | а | к | ә | н | ө | г | х | я | а | и | н | а | р | ү | в |
| е | ы | к | а | е | з | л | ө | т | к | а | к | у | ң | о | ы |
| а | в | к | р | у | а | к | к | и | т | у | о | ә | а | г | к |
| а | р | е | к | к | о | ө | н | н | р | к | ч | с | ы | л | ы |
| я | с | у | е | у | к | ә | а | ә | ы | е | а | е | л | а | н |
| ә | г | ш | а | р | т | т | а | н | а | к | ы | ә | к | р | р |

«Нурчыклар» гәҗитен гамәлгә куючы:
Татарстан Республикасы Буа шәһәренең катнаш төрдәге "Кояшкай" балалар бакчасы" муниципаль бюджет учреждениесе

Редколлегия әгъзалары:
Гыйниятуллина Д.Р.
Шакирова Г.Р.

Безнең адрес:
422430, Буа шәһәре,
Арефьева урамы, 13 йорт

Тел. (843)743-13-09
E-mail: colnush-bua@mail.ru